

Сигезенче июльдә Республика йортында Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык конено багышланган тантаналы чара узды.
Тантанада Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов аерым билгеләп vткәнчә: «Дус, нык, кvп буынлы гаиләләр дәvләтебезнен киләчәген билгели, аларда боек Россиянен чәчәк атуынын гарантиясе бар.
Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин бу елны Гаилә елы дип игълан итvе очраклы тvгел. Без аны республикада хезмәт династияләре Елы чаралары белән тулыландырдык.     Республикада кvп балалы гаиләләр саны арта - оч ел эчендә аларнын саны 10 процентка, ә инде 10 ел эчендә карасан, аларнын саны ике тапкырга диярлек артты. Без тууны арттыру һәм балалы гаиләләргә ярдәм итv программасын гамәлгә ашыра башлыйбыз. Муниципаль районнарнын берсендә пилот проектын эшләтеп жибәрәбез. Эш бирvчеләр, барлык жәмәгать институтлары, табиблар белән яшь гаиләләрнен игътибарын жәлеп итv, vз сәламәтлегебезне генә тvгел, ә булачак балаларнын сәламәтлеген дә саклау очен эшләячәкбез.
Гаилә елы старты кvп балалы гаиләләрнен статусын кvтәрv һәм социаль ярдәм кvрсәтvгә кагылышлы Президент Указы белән билгеләп vтелде. Бездә Указнын нигезләмәсенә республиканын 40 мен кешесе кагылды. Балаларны лаеклы тәрбияләvче барлык гаиләләргә рәхмәт. Үги балалар турында кайгыртуны vз остенә алган кешеләргә аерым рәхмәт. Бу зур йорәкле әниләр һәм әтиләр. Сезнен алда башны тvбән иябез!».
Чыгышынын бер олешендә Артём Алексеевич махсус хәрби операциядә илебезнен куркынычсызлыгын һәм киләчәген батырларча саклаучы ир-егетләребезнен гаиләләре аерым игътибар vзәгендә, ди. Алар – безнен хәрбиләребезнен рухи коч чыганагы, ышанычлы терәге һәм таянычы.
Бәйрәмгә республиканын гаилә парлары чакырылган. Тантаналы рәвештә аларга Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов, Мордовия Республикасы Дәvләт Жыелышы Рәисе Владимир Васильевич Чибиркин, Мордовия Хокvмәте Рәисенен беренче урынбасары Галина Алексеевна Лотванова бvләкләр тапшырган. Татар милләтле гаиләбез дә vз бvләген алды. Шулай, Ринад кызы Камилла белән Юнир улы Марсель Ишкиняевларга, башка гаиләләр арасында, Мордовия Республикасы Главасынын “Балаларны тәрбияләvдәге хезмәтләре очен” (“За заслуги в воспитании детей”) Мактаулы дипломы белән бvләкләнгәннәр.
Дvрт балалы (Самат, Данис, Амалия, Алан) гаилә башы Марсель Юнир улы Ләмберә

халыкы социаль яклау идарәсе водителе, ә хужабикә - Камилла Ринад кызы Ләмберәнен беренче мәктәбендә математика фәнен укыта. Алар һәркемнен хыялы, омтылышы, терәге булган нык, тату гаилә учагын сvндермичә яшиләр. Бу гаиләнен мәхәббәте, бер-берсенә булган тугрылыклары тормыш юлларында очраган кыенлыкларны жинәргә коч бирә, ният-максатларын тормышка ашырырга ярдәм итә. Камилла Ринад кызы белән Марсель Юнир улы Ишкиняевлар гаиләсендә халкыбызнын асыл сыйфатлары, гореф-гадәтләре саклана һәм буыннан-буынга тапшырылып килә.